МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.02.2026 № 15-9

г. Казань

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына килеп ирешкән Гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсе нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына килеп ирешкән Гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә анализ ясауның кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының эш башкару бүлегенә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына килеп ирешкән Гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә ярты еллык һәм ел йомгаклары буенча анализ ясарга.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Гражданнардан килеп ирешкән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибен раслау турында» 2015 елның 25 сентябреннән 15-94 санлы боерыгын үз көчен югалткан дип таныргa.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр М.Ж.Фәйзрахманов

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгы боерыгы
белән расланды
06.02.2026 № 15-9

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына
килеп ирешкән Гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына гражданнар һәм оешмалардан килеп ирешкән мөрәҗәгатьләргә (алга таба – мөрәҗәгатьләр, Министрлык) анализ ясау механизмын билгели.

2. Мөрәҗәгатьләргә анализ мөрәҗәгатьләрне карау эшенең сыйфатын күтәрү, җәмәгатьчелек фикерен һәм гражданнарның актуаль проблемаларын өйрәнү, мөрәҗәгатьләр белән эшләү рәвешләрен һәм алымнарын камилләштерү һәм гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын арттыру максатларында үткәрелә.

3. Анализ гражданнарның идентификациясен һәм (яисә) аутентификациясен тәэмин иткән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын яисә Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтын (https://minfin.tatarstan.ru/) (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) кулланып, язма рәвештә, электрон документ рәвешендә, шулай ук Татарстан Республикасы финанс министры (алга таба – министр), министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары (алга таба – гражданнарны шәхсән кабул итү буенча вәкаләтле затлар) тарафыннан гражданнарны шәхсән кабул итү барышында килеп ирешкән ярты еллык һәм ел дәвамында каралган мөрәҗәгатьләр буенча башкарыла.

4. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау Министрлыкның эш башкару бүлеге тарафыннан электрон документ әйләнеше белешмәләре нигезендә ясала.

5. Мөрәҗәгатьләргә анализ ясау нәтиҗәләре буенча Министрлыкның эш башкару бүлеге ярты еллыкның, елның соңгы аеннан соң килүче айның 13 числосына кадәр аналитик белешмә төзи.

6. Аналитик белешмәдә килеп ирешкән, яңадан адресланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләрнең саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнарның саны, гражданнарны шәхсән кабул итү һәм шәхси күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы,

мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар (булган очракта) турында мәгълүмат булырга тиеш.

7. Министрлыкның эш башкару бүлеге аналитик белешмәне, шулай ук билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагыла торган аеруча актуаль мәсьәләләр буенча аңлатмаларны Министрлыкның рәсми сайтында «Халык мөрәҗәгатьләре өчен» бүлегендә ярты еллыкның, елның соңгы аеннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштыруны тәэмин итә.